

## Муллахметова Әлфия Рәхимҗан кызы

район методика кабинеты мөдире булып 1996 нчы елның 2 сентябреннән 2011 елның 1 февраленә хәтле эшләде. Ул эшләгән 15 ел дәвер зур структур үзгәреш чоры булды, бөтен мәгариф системасында үзгәртеп корулар булды; методик эш, белем сыйфатының дәрәҗәсен тикшерүнең яңа методларын кертү, информатизация. Коллективта эшләгән һәр ИМЦ специалистына яңа эш юнәлешләрен үзләштерергә, эш практикасына кертергә туры килде. Бу елларда район мәгариф системасы республика күләмендә танылу алды. Методик эшне оештыру, аттестациягә әзерләү һәм аны үткәрү, алдынгы тәҗрибәне барлау һәм тарату, укыту-тәрбиянең нәтиҗәлелегенең югары дәрәҗәдә булуы республика масштабында билгеләп үтелде. Мәгарифнең нинди өлкәләре үзгәртүләргә дучар ителде соң?

Бу, беренчедән, белем бирүнең эчтәлеген яңарту булды. Укыту планнарының күптөрлелеге, профильле укытуны кертү, 2 нче сыйныфтан башлап чит тел өйрәнү, милли компонентны баету, интегратив курслар, мәктәп компоненты һәм б. Бу юнәлешләр барысы да белем сыйфатын күтәрергә ярдәм итәргә тиеш иде. Шуңа күрә мәктәп җитәкчеләренә тиешле кадрларны табу, укыту планын озак перспективага дөрес итеп сайлау, мәктәп компонентын эффектлы итеп куллану кирәк иде. Бу юнәлештә Кадыбаш урта мәктәбе, Сарсак-Омга лицее, гимназия №1 үз йөзләрен таба алдылар.

ПНПО проектын гамәлгә ашыру иң яхшы мәктәпләр, укытучыларны билгеләү, аларның эшчәнлегенә яңа күзлектән карарга этәрде. Методик эшне оештыруда эчке резервларны гына түгел, ә яңа формаларын эзләргә мәҗбүр итте. Шулай ук, район администрациясе дә бу өлкәдә республикада иң беренчеләрдән булып, иң яхшы мәктәпләрне материаль бүләкләүләр кертеп, яхшырак эшләргә этәрде. Сарсак-Омга лицее, гимназия №1, Әгерҗенең 2нче номерлы мәктәбе миллионер мәктәпләр булдылар. Маркитонова Л.Л., Панфилова Л.А., Зиннатуллина Э.Х., Бурганиева Ә.Р., Кондрашина Е.В., Шамшурина Т.М. һ.б. 100 мең сум грант алуга ирештеләр. Бу укыту-белем бирү учакларының һәм аерым педагогларның эшчәнлекләренең сыйфаты югары булуын, инновацион алымнар кулланып эшләү, алдынгы тәҗрибәләрнең республика һәм Рәсәй күләмендә билгеле булуы, таралуы аркасында булды.

Мәгарифне информатизацияләү эшне җайлауга бер этәргеч булды. Информатика фәнен укытучылар әзерләү, ул катлаулы техниканы укыту-тәрбия процессына кертү һәм аны аралашу чарасына әйләндерү максаты куелды. Укытучылар Ишпаева Г.Б., Сисина Г.А., Гиззатуллина А.Ш., Бурганиева Ә.Р. беренчеләрдән булып бу фәнне укыта башладылар.

Бу елларда белем сыйфатының дәрәҗәсен тикшерүдә БДИ (ЕГЭ), ГИА (ОГЭ) яңа ысул кулланыла башлады. Аның кертелүе методик эшне оештыруда яңа юнәлешләр барлыкка китерде. Элек укытучының профессиональ осталыгы методика, дидактика өлкәләрен белүне таләп итсә, хәзер төп басым предметны белүгә ясалды. Шуңа күрә ИМЦ белгечләреннән ныклы аналитик эшчәнлек соралды, проблемалы темаларны табып, шуларны үзләштерүнең эффектлы алымнарын табып өйрәтү бурычы да куелды. Рус теле, математика буенча безнең район һәрвакыт урталыкта булды. Бигрәк тә Сарсак-Омга, Кичкетан лицейлары, Көчек, Кадыбаш, Бима, гимназия №1, шәһәрнең 2нче мәктәбе яхшы

нәтиҗәләргә ирештеләр.БДИ, ГИА укытучыларны гына түгел, укучыларны, аларның ата-аналарын да уятты, белем алуга карашларын үзгәртте.

Районда методик эш перспектив стратегик планлаштыруга нигезләп алып барылды. Соңгы 10 елда 2 тапкыр "Район мәгариф системасын үстерү, информацион-методик эшне камилләштерү программасы" район сессиясендә расланды. Һәр эшләгән эш нигезле, "үз йөзле", мәктәпләр, балалар бакчалары һәм педагоглар өчен кирәк һәм мөмкин булганча финанслар белән ныгытылган иде.

Һәр белем бирү учреждениесе үзенең проблемаларын билгели ала иде һәм аны чишүне фәнни нигезгә корып, системалы итеп, билгеле бер нәтиҗәгә килерлек итеп оештыра иделәр. Проблемалар дәлилләнеп, мәктәп ихтыяҗыннан чыга иде. Девятерня, Кичкетан, Бима, Кулегаш, Үтәгән, Әгерҗенең 1нче, 2 нче мәктәпләре проблема буенча эшләүләрен семинарларда, яшь җитәкчеләр өчен оештырыла торган укуларда, август киңәшмәләрендә сөйләделәр. Район педагогларының эш тәҗрибәсе 2 тапкыр "Мәгариф", 2 тапкыр "Фән һәм мәктәп", "Открытый урок" журналларында басылды. Үзләренең эшкәртмәләре белән безнең укытучылар "Народное образование", "Учительская газета", "Иностранный язык в школе", "География в школе", һ.б. педагогик нәшриятларда бастырдылар. Укытучылар фәнни эштә дә актив катнаштылар. Төрле авторлык программалары, укыту-методик әсбаплары конкурсларында катнаштылар, 1нче һәм 2 нче дәрәҗәдәге дипломнар белән бүләкләнделәр. Министр Ф.Ф.Харисов катнашкан август конференциясендә оештырылган "Мәгариф һәм сәламәтлек", Президент М.Ш.Шәймиевнең районга визиты вакытында күрсәтелгән "Техник иҗат" күргәзмәләре югары бәя алды.

Район методик кабинеты алдынгы тәҗрибәне өйрәнү, барлау һәм тарату өстендә дә зур эш алып барды. Тупланган материаллар республика дәрәҗәсендә танылу таптылар. Шуңа күрә югары категориягә аттестация узу да катлаулы булмады.